**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2024 елның «27» сентябреннән № 247

«Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «Гражданнар оборонасы, халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән яклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләр иминлеген тәэмин итү өлкәсендә Яңа Чишмә муниципаль районы хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2017 елның 14 сентябрендәге 466 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында»

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 елның 14 августындагы 569 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасында бюджетара мөнәсәбәтләрне формалаштырганда исәпкә алына торган гражданнар оборонасы, халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән яклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләр иминлеген тәэмин итү өлкәсендә Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары бюджетларының хезмәт өчен түләү чыгымнары күләмен билгеләү методикасынын 2 нче кушымтасына үзгәрешләр кертү турында» 2024 елның 12 сентябрендәге 780 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «Гражданнар оборонасы, халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән яклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләр иминлеген тәэмин итү өлкәсендә муниципаль берәмлек хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2017 елның 14 сентябрендәге

466 номерлы карарына (Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 9 гыйнварындагы 1 номерлы, 2020 елның 30 октябрендәге 271 номерлы, 2022 елның 10 октябрендәге 283 номерлы, 2024 елның 21 маендагы 144 номерлы карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешне кертергә:

күрсәтелгән карар белән расланган гражданнар оборонасы, халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән яклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләрнең иминлеген тәэмин итү өлкәсендә муниципаль берәмлек хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәдә:

II бүлекнең 1 таблицасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1 таблица

| № т/б | Хезмәткәрләрнең вазыйфалары | Вазыйфаи окладның күләме, сумнарда |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 1 | Оешма җитәкчесе | 27 560 |
| 2 | Оператив дежур торучы | 21 200» |

2. Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасарына (икътисад буенча) йөкләргә.

Җитәкче Р.Р. Фасахов